3 нче февраль  көнне безнең лицейда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына  багышланган чара үткәрелде.
Мәкаль һәм әйтемнәрдә ана телебезнең матурлыгы һәм камиллеге, төгәллеге һәм байлыгы гәүдәләнә. Халык үзе болай ди: «Әйтем – сүзнең бизәге, мәкаль – сүзнең җилеге». Мәкальләр, әйтемнәр кешедә фикерләү сәләтен, зиһенен үстерә, акылын, тапкырлыгын тирәнәйтә, телгә мәхәббәт тәрбияли. Туган тел һәм әдәбият укытучысы Альбина Маликовна бүген үткәрелгән дәрестән тыш чарада нәкъ шуны балалар алдында ачыклады.

